| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ТЕЛӘЧЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«29» сентябрь 2025ел № 135

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 14 июлендәге 94 номерлы «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 353-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 14 июлендәге 94 номерлы «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына (27.08.2025 № 116 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган Муниципаль милектәге җир кишәрлеген алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына:

А) 2.5.2 пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән бакчачылык яисә коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәте әгъзалары Реестры, мондый ширкәткә җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү яисә җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирү турында гариза бирелгән очракта.»;

Б) 2.8.3.2 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге бакчачылык яисә коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән, моңа ширкәт әгъзасының (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачылык яисә яшелчәчелек

ширкәтендә катнашу (әгъзалык) хокукына ия булмаган граждан мондый гариза белән мөрәҗәгать иткән очраклар керми, федераль законнар нигезендә җир кишәрлеген беренче чиратта яисә чираттан тыш сатып алу хокукы булган ширкәт, Россия Федерациясе субъектлары законнары белән яки Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 статьясы нигезендә җир кишәрлеге сатып алуга (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачылык кишәрлеге булса), шулай ук гражданнар бакчачылык яисә яшелчәчелек алып барган территория чикләрендә үз ихтыяҗлары өчен урнашкан җир кишәрлекләре милекчеләреннән тыш (әгәр җир кишәрлеге гомуми билгеләнештәге җир кишәрлеге булса);»;

В) 2.8.3.2 пунктның 13 пунктчасында «хуҗалык» сүзеннән соң «торак пунктлар чикләрендә» сүзләрен өстәргә;

Г) 2.8.3.2 пунктның 16 пунктчасында «чикле» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru һәм Теләче муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга: https://tulachi.tatarstan.ru.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин